Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**2010 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын раслау турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 3 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең законнар чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында" 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2010 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативлары (алга таба – нормативлар) күләмнәрен әлеге Закон кушымтасы нигезендә расларга.

**2 статья**

Нормативларны үзгәртү Бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре беренче разрядының законнар нигезендә билгеләнгән хезмәт хакы ставкасының база өлешен һәм (яисә) тариф ставкасын (окладын) үзгәртү белән бер үк вакытта башкарыла.

**3 статья**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән "2009 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын раслау турында" 2009 елның 22 октябрендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 11) үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

Әлеге Закон 2010 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 26 декабре
№ 69-ТРЗ